## Бәзәкә клубы үзешчәннәре турында истәлекләр.

2017 елның 11 ноябрендә Бәзәкә авылы мәдәният йортынының 50 еллыгына багышланган юбилей кичәсе булып үтте. Аны әзерләп, матур итеп үткәргән Гүзәлиягә, Розалиягә, Фәниягә һәм аларның күп санлы дусларына зур рәхмәтемне белдерәсем килә.

Бу очрашу, куңелнең йомшак кылларын тибрәтеп, балачак һәм яшьлек елларына алып кайтып китте, чөнки минем дә тормышым үзешчән сәнгать белән озак вакытлар бәйләнештә булды. Аның башы балалар бакчасында башланса, аннан соң мәктәп елларына кереп китте. Анда инде мин Әдия апа Ибраева кулына килеп кердем. Ул шулкадәр балаларны һәм эшен яратучы, шундый ягымлы, нечкә күңелле, дәртле, һәр баланың җаен табып эшләүче кеше иде. Мин аның беркемгә дә кычкырганын, начар карашын белмим. Нинди түзем булган ул!!!

Әниләрнең чаршауга дип алган ситцасыннан сарафаннар тегеп, башка тасмалардан чәчәкләр тезеп, такыялар ясап киеп, Әдия апа өйрәткән рус, украина  биюләрен бии идек. Фотода да калган бу хәл тарихка тереп: анда шул сарафаннар киеп дүрт кыз төшкәнбез- Насифуллина Тәскирә, Аглиева Гөлфания, мин һәм Гимазетдинова (Мөхетдинова) Рәмзия. Әдия апа белән куйган концертлар, кичәләр клубта үтә иде.

Элеккеге клуб агачтан салынган, сәхнәдән һәм бер зур гына залдан торган йорт. Залда агач скамейкалар тезелгән, кичен танцылы кичәләр вакытында алар стена буена җыеп куела, зур гына түгәрәк ясала,  җыелган яшьләр бии. Ул өйнең, русча итеп әйтсәк, кечкенә генә икегә бүленгән пристрое бар.  Аның бер өлешендә Олы әби тора, клубны саклап, җыештырып. тәртип саклау аның вазифасына керә. Аның исемен мин белмим, без барыбыз да аны шулай дип атый идек. Ул берүзе шунда тора, зур миче бар. Без, артистлар, кичен шунда җыелабыз. Олы әби торган яктан яңа пешкән тәмле аш исләре чыга. Зур апалар, абыйлар үз аралай уйнашып та алалар. Мин кечкенә, миңа кызык. Сәхнәгә чыгу өчен биек кенә баскычтан менәргә кирәк. Хәзер дә ул клуб минем төшләремә керә.

Исемдә Әнисә апаның (Чагина) нечкә генә тавыш белән җырлаганы. Ни өчендер Зиннур абый (кушаматы Былбыл, фамилиясен белмим) исемә төшә. Ул яңа гына солдаттан кайткан, моряк формасында йөри. Ялгышмасам, ул баянда уйный һәм

җырлый иде. Мин ул чагында 8 класста укый идем. Зиннур абый, армиядан кайтач, безнең белән укыды. Безгә кызык та, кызыклы да - зур абый безнең белән, парта артында утырып, җавап бирә, диктантлар яза... Уку турында документ кирәген әйтә торган иде.

Шул 8 класста укыганда классташым Нуретдинова Гөлсинә белән җырларга уйладык. Ул вакытта модада булган “Умартачы сөйгәнем” белән “Молодой моряк” дигән җырларны сайладык, җиңел дә җырлана. Җырладык!.. Икенче көнне Рәшит абый Башаров, бөтен класс алдында бастырып, кирәкне бирде: “Оялмыйча, авыз күтәреп, умартачы сөйгәнем дип, бөтен кеше алдында җырларга ничек башыгыз җитте? Аның өстенә : “На побывку едет молодой моряк”. Сез бит әле бала гына андый җырлар җырларга!”- дип сүкте. Хәзерге укучыларны күрсә ни дияр иде икән ул? Дөнья ничек үзгәрде!!!

Зуррак классларда дүрт егет һәм дүрт кыз “Молдавский ңок” дигән молдован биюен өйрәндек. Башта әкренрәк башлана, аннары кызурак була башлый, ә аннан соң бик кызу китә, өлгер генә!! Җәйләрен, үзешчәннәрне җыеп, җәйләүгә сыер савучыларга һәм башкаларга концерт күрсәтергә алып китәләр иде. Грузовой машинага төялеп, барлык сикелтәләрне санап, кыр буйлап чабабыз бер елны барыбызга да прививка ясадылар. Бик авыра торган булды. Кайсыбызның аркага калак сөяге астына салганнар, кайсыбызның беләгенә. Ул бик каты шешеп чыккан, кып-кызыл, ә кайсыбызның үлекләгән дә, кул тигереп тә булмый. Машина өстендә барганда да, еларга җитеп, кычкыра-ыңгыраша барып җиттек. Машинадан күтәреп төшерделәр. Хәзер теге молдаван биюен башкарасы бар бит! Рус, татар биюендә кулларны бик күтәрмәсәң дә була, ә бу биюдә куллар кырыйдагы кешенең җилкәсендә булырга тиеш. Куллар белән тотынышып әкрен генә чыгабыз, көй кызулана башлый, кулларны күтәреп, иелә-сыгыла җилкәләргә куябыз, тотынабыз кызу-кызу биергә. Кайсыбыз авыртудан агарган, кайсыбыз кызарган. Аның өстенә көне эссе, үзебезнең температура 40ка җиткән. Бии торган урын да сәхнә түгел, ә җир, ул тигез түгел, аякка үлән урала. Шулай итеп, ничек булса да концерт куеп кайттык. Ничек берәр нәрсә булмаган? Шундый хәлдә ул биюне әллә ничә тапкыр биергә туры килде. Яшьлек булганга күрәдер инде, үзебезгә күңелле, көлгән булабыз.

Укытучылар куйган спектакльләр турында Рәмзия Мөхетдинова үзенең китабында бик матур итеп язган, кабатлап тормыйм. Кайбер

истә калганнар турында язып үтәсем килә, аеруча “Зәңгәр шәл” спектакле турында. Әни белән Наҗия апабыз ишан янына барган карчыкларны уйныйлар. Нәрсә һәм ничек киярргә, ничек уйнарга дип бәхәсләшәләр, авыл буйлап карчыклардан элеккеге күлмәкләр җыялар, ишанга бирергә әллә ничә дистә йомырка, савыт белән сөт алып киттеләр. “Өйдә берүзем калырга куркам”,- дип, әнигә ияреп клубка килдем. “Шуннан чыкма”, - дип бер почмакка утыртып куйды мине әни. Мәйсәрәне укытучы Сабира апа уйный, ул бик чибәр иде. Аның усал абыйсын директор Гимадиев Муллаян абый уйный. Ул балта белән Мәйсәрәгә ыргытырга тиеш. Бөтен нәрсә дә чын булырга тиеш бит, хәзерге кебек муляжлар түгел. Ялтырап торган чын балта белән җибәрде Мәйсәрәгә. Балта, чыжлап, Сабира апаның башы яныннан очып китте, бөтен халык аһ итте. Ә инде Булат ролен уйнаган Хәй абый Гильфанов җырлап җибәргәч, бар кеше дә таң калды. Бөтен яктан да шундый талантлы булса булыр икән!!! Мин мәктәпкә укытырга кайткач, “Казан сөлгесе” спектаклен куярга уйладык. Хәй абый миннән анда үзе җырларга тиешле җырның көен сорады. Мин җырлап күрсәттем. Минем көй бераз гына дөрес түгел икән. Икәү бераз бәхәсләшкәннән соң, ул миңа дөрес түгеллегемне танытты. Хәй абый барлык нәрсәне дә нечкәлекләренә кадәр өйрәнә, тикшерә иде.

Без институтка укырга кергәч, иске клубны сүтеп, яңасын салып куйдылар. Аңа бик озак ияләнә алмадык – танцевать итәргә залы кечкенә, тар, шыксыз булып күренде, вальс әйләнергә урын җитми. Модага магнитофон кереп китте, баян кысырыклап чыгарылды. Без кызып кына современный биюләр биегәндә олы апалар килеп кērә дә: “Туктатыгыз ул доңгырдыгыгызны, безгә гармун кирәк. Кая, Хәким, уйнап җибәр әле, безнең дә биисебез килә”, - диюгә Хәким, кулына баянын алып, татар бию көйләрен сыздырып уйнап җибәрә. Башта абый-апалар берәмтекләп, үзләренчә, элеккечә – гармунчы янына тыпыр-тыпыр итеп киләләр дә, аның алдында башларын иеп куялар да җиңел генә яңадан биеп китәләр. Аннан башлана парлы бию, өчле бию һәм башкалар. Бөтен халык ду килеп, тирләп-пешеп, хәлдән тайганчы бии.

Киноларны башта Вәгыйз абый күрсәтте. Аннары Хикматуллина- Гыйлметдинова Хәмдия, Казаннан укып кайтып, киноларны ул күрсәтә башлады. Һиндстан киноларын күтәп ала идек. Хәзерге кебек, нинди кино карыйсың килсә, шуны күреп булмый иде шул. Икешәр сеанс була иде: иртәрәге балалар өчен,

аннары зурлар өчен. Аннан соң гына яшьләр танцыга кала. Гомумән, бию кичәләренә кичке сәгать 11дә генә чыга идек, өйгә төнге 1-2дә генә кайтып авабыз.

Ул вакытларда эшләре өчен янып йөргән (Әдия ападан кала) өч кеше йөрәгемдә уелып калган: Вәгыйдә апа, Хәким һәм Нәкыя. Юбилей кичәсе алдыннан Вәгыйдә апаның кызы Лилия белән кочаклашып күрештек, озаклап сөйләшеп торырга вакыт кына булмады. Мин аны әнисе аркасында үземнең туганым кебек күрәм, хөрмәтем дә зур аңа: авыру әнисен соңгы көненә кадәр бик тырышып карады, гомерен озынайтты. Ул сәхнәгә чыгып җырлаганда түзә алмыйча еладым.

Вәгыйдә апаның тормышы җиңел булмады, шуңа күрәдер инде бик моңлы итеп җырлый иде. Аның тавышына сокланмаган кеше калмады. Кызы Лилиянең дә тавышы бик матур икән. Ул җырлаганда Вәгыйдә апа белән концерт куеп йөргән вакытлар искә төште. Кеше белән эшләү, аның көен табу бик авыр нәрсә бит ул! Һәрбер “артистка” ялынырга кирәк, күбесе, үзен әллә кемгә куеп, ялындырырга ярата. Аның сәбәбе дә чыгып тора: я миңа аның өчен акча түләмиләр, я минем вакытым юк, я гаиләм җибәрми... Безнең авыл халкы бик кырыс бит, алар да йөрәккә тоз салып торалар: я клуб мөдиренең акчасын саныйлар ( күп алалар, эшләсеннәр, имеш), я җитәрлек эшләмиләр, я эшләре ошамый... Үзләре ул эшкә катнашмаганнар теләсә нәрсә сөйләп йөри дә инде. Кайберсе: “Менә без эшләгәндә...”, - дип тә әйтеп җибәрә. Критика урынына булышсалар, ачу тотып йөрмәсәләр үзләренә дә, кешегә дә файдалары күбрәк тияр иде. Ул хәзер дә шулай, элек тә шулай булды. Вәгыйдә апаның да күпме җанын ашадылар. “Мин аның эшен бик яратып эшләр идем, ну шул усалларның теленә чыдап булмый”, - ди торган иде. Кеше мәңгегә килмәгән бит, матур гына, эшләгән эшләрне күреп, бер-береңне хөрмәт итеп яшәргә булмый микәнни соң? Ире Мансур абый баянист иде, аның көенә дә торырга кирәк булды. Шуңа күрә дә, бәлки, иртәрәк китеп баргандыр Вәгыйдә апа. Шулар барысы да күз алдыннан узганга концерт вакытында елаганмындыр инде.

Ярар, эшләнгән эшләргә күчик. Исемдә, җиңү бәйрәменә әзерләнгән концерт куйдык. Сәхнәдә мәңгелек ут ясап куйдылар, хор “Солдатлар “ җырын башкара. Мәңгелек ут янына карадан киенгән сугыштан кайтмаган солдат анасы ролендә Вәгыйдә апа

чыгып, мәңгелек ут янына басып, җырның бер куплетын башкарды. Халык үкси-үкси елады.  Урының оҗмахта булсын, Вәгыйдә апа!

Вәгыйдә ападан соң, Алабуга культпросветучилищесын бетереп, Хәким безгә эшкә килде.. Ул бик шәп гармунчы, организатор булып чыкты. Аңа ярдәмгә Нәкыя килде. Менә башланды эш! Нәкыя хәзерге кебек бик тынгысыз бию остасы иде. Безгә бер тынгылык та бирмәде: бию группасын оештырды, әллә нинди без күрмәгән, ишетмәгән биюләр өйрәтә башлады. Авылча гына биергә өйрәнгән яшьләргә ул яңа биюләр бик ошый иде. Без Сәләхи белән бик күп биюләр куйдык. Нәкыя безгә керәшен биюе өйрәтте. Өйрәнүен өйрәндек, хәзер костюм табарга кирәк. Сәләхигә җайлы, әллә ни кирәкми. Ә миңа каян алырга? Сәйтәктән алып кайтсаң гына инде. Әтинең Җәгүр бабай дип йөргән дусты бар. Мин әтигә аннан костюмны каян табарга булуы турында сорарга куштым. Әти: “Сөйләштем, барып ал,”- диде. Киттем Сәйтәккә. Әти аңлаткан өйне таптым. Җәгүр дәдәйнең хатыны өйдә. “Минем юк, күршедән сорап карыйм”,-дип чыгып китте. Байтак кына көткәч, костюм күтәреп кайтып керде. “Берүк барысын да алып кайтып бир. Хаҗи абый кызы булганга гына ышанып бирделәр”,- дип, кулга бик авыр костюм бирде, ничек кияргә кирәклеген аңлатты, чөнки ул күлмәк бик катлаулы булып чыкты. Ул костюмдагы тәңкәләр патша акчаларынннын гына тора иде. Мондый костюм миңа бүтән эләкмәс дип, Алабугага алып барып, фотографиядә фотога төштем. Андагы егетләр:”Бер генә тәңкә булса да бүләк ит инде”,- дип теңкәгә тиделәр. Ул костюмның нинди кыйммәтлеген мин соңынан гына аңладым. Сәләхи белән бик озак биеп йөрдек, институтта да бергә биештергәләдек. Мәдәният йортының юбилеена кайткач та: “Нигә Сәләхи белән биемәдегез, сезнең биюегезне дә күрербез дип чыккан идек”, -дип килеп әйтүчеләр булды. Картаелды шул инде...

Мин авылга укытырга кайткач, Мухаметзянова Гөлсинә белән икебезне радиодан кичке тапшырулар алып барырга куйдылар. Гөлсинә колхоз яңалыклары турында сөйли, мин күңелле өлешенә җаваплы: җырларга, шигырьләр укырга кеше җыям.килмәсәләр, үзем укыйм, үзем  җырлыйм. Миңа булышырга Ахметзянова (Хурматуллина) Саяра килә, ул да җырлый. Аның тавышы үзе кебек бик матур иде.

Авылда хатын-кыз трактор бригадасы төзелеп, даннары еракларга таралгач, Москвадан “Крестьянка”  журналыннан килеп, аларны карточкага төшерәләр дигән хәбәр таралды. Үзешчәннәргә

дә җыелырга куштылар. Клуб янында үскән каеннар янына җыелдык. Районда клуб эшен бик мактап сөйләгәннәр, шуңа күрә безне дә төшерергә уйлаганнар. Ул вакытта Хәким оештырган баянистлар группасы бар иде, аларны карточкага төшерделәр. Сабитов Рафаез абый, Башаров Фәрит, Хәким үзе һәм башкалар бар иде анда. Алар кырыенда Сабитова Роза апа җырлап тора. Калганнарны җыеп клубка алып кереп киттеләр. Бер төркем кешене сәхнәдә төшерделәр: мин укып утырам, Гыйлфанова Тәскирә (Фәйзелхак абыйның кызы) Габдуллина Гүзәлгә яулык бәйли, Рафаез абый белән бер кыз сөйләшеп тора... Шулай итеп, без илдә танылган кешеләргә әйләндек. Миңа да төрле җирләдән берничә егеттән хат килде. Әле дә апалар көлеп исләренә төшергәлиләр.

Әдия апа, Вәгыйдә апа, Хәким, Нәкыя белән эшләгәндә район буенча беренчелекне без беркемгә дә бирмәдек. Менә шулай гөрләтеп яшәдек, искә төшерерлек эшләребез, истәлекләребез бар!

Шушы истәлекләргә бәйләп шуны әйтәсем килә: хәзер дә без һәм безгә кадәр кабызган утлар сүнмәгән, оештыручылар һәм аларның булышчылары бик тырышып эшлиләр, байракны югары тоталар. МОЛОДЦЫ!!! ТАК ДЕРЖАТЬ!!!

*Мәхмүтова Әнисә, Алабуга*



1 Үзешчән сәнгать активистлары: “Крестьянка” журналынннан





Аглиев Зайнак абый белән



Нәкыя белән



Концертка әзерләнгәндә.  Сулдан уңга Насифуллина Тәскирә, Аглиева Гөлфания, мин, Рәмзия



Сәләхи белән татар биюе



Алабугада куйган концерт белән Бәзәкәгә дә килдек. ЕГПИ студентлары Сөләйманова Илсөяр, Нуриева Светланга, Мәхмүтова Әнисә.




азований ер-
встр



Бу концерты да Бәзәкә сәхнәсендә күрсәттек.


Ибатуллина Шәргыя, Гильфанова Зәйтүнә, Кулячева Мәүлия, Ибраева Әдия



Аликин Нурулла абый Бәзәкә кызлары белән концерт куялар



Мәктәп укытучыларының концерты: Хаҗиәхмәт белән испан биюе башкарганда. 1974 ел.февраль.


Чын керәшен костюмы – Сәйтәктән, Сәләхи белән керәшен биюен биедек.

Участники художественной самодеятельности колхоза в этом году вышли победителями в районном смотре.

Фото Р. МЕРСОНА.



Фото 1: баянисты слева направо- Гиззатуллин Ильгиз, Башаров Фарит, Гимазетдинов Муллаян, стоят- Гиззатуллин Ильяс и Ахметзянов Нургали. Стоят слева направо- Сабитовы Рафаиз и  Роза, на заднем плане- Наиля…(живет в Сибири), вторую не знаем (фото из журнала «Крестьянка», первая половина 70-х годов).



Фото 2: Баянист Мансур Гильфанов и певец Рафаиз Сабитов (конец 70-х годов).



Фото 3: Татарский танец. В середине- Роза Сабитова (начало 70-х годов).




Фото 4: Баянист Гимазов Дамир, вокальный квартет- Сабитовы Рафаиз и Роза, Гимашева Рамзия, Сабитов Мехаматнур (конец 70-х годов).



Фото 5: Вокально- инструментальный ансамбль- гитара (не видно), вокал Саляхи Тазиев, ударные Рафаиз Сабитов, баян Мансур Гильфанов.